**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**Староматакского сельского поселения Алькеевского муниципального района**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**Әлки муниципаль районы**
**Иске Матак авыл Жирлеге**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Адрес: 422890, РТ, с. Старые Матаки, ул. Центральная, 4
тел: : 8 (84346) 24-3-03

Адресы: 422890, РТ, Иске Матак авылы, Узек ур., 4
факс: 8 (84346) 24-3-03

ПОСТАНОВЛЕНИЕ Иске Матак ав. КАРАР

2025 елның 09 июне № 9

Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Иске Матак авыл җирлеге территориясендә йорт хайваннарын йөртү урыннарын билгеләү турында

06.10.2003 елның 131-нче Федераль Законы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында», 27.12.2018 елның 489-нче Федераль Законы «Хайваннар белән җаваплы эш итү һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында», Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының «Иске Матак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы таянып, Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Иске Матак авыл җирлеге Башкарма комитеты **КАРАР КАБУЛ ИТӘ:**

1. Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының «Иске Матак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә йорт хайваннарын йөртү өчен түбәндәге урыннарны билгеләргә:

1.1. Файдаланудагы яисә хуҗа милкендәге җир кишәрлекләре;

1.2. Халык күпләп җыелмый торган авыл җирлеге территориясендә торак сектор һәм җәмәгать урыннары артындагы урыннарда, борындыкларда һәм тезгендә аларның хуҗалары күзәтүе астында:

- Иске Матак авылының төньяк-көнчыгыш өлешендә 100 метр ераклыкта Чапаев ур. буйлап;
- Югары Матак авылының көньяк-көнбатыш өлешендә, Ленин урамыннан 200 метр ераклыкта;
- Чуаш Шәпкәсе авылының көньяк-көнбатыш өлешендә, Үзәк урам буйлап 200 метр ераклыкта

Бу территорияләрдә «Йорт хайваннарын йөртү»дигән язулы табличкалар урнаштырырга.

2. Әлеге карарны "Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында" түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru хәм Әлки муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Әлки муниципаль районының
Иске Матак авыл җирлеге
Башкарма комитет җитәкчесе О. Г. Гуляева